Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Советы

Шигали авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

29 июль, 2025 ел № 12

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 29 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы карарының 4.2 пункты, Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 6 номерлы карары белән расланган нигезләмә (2017 елның 14 декабрендәге 19 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 11, 2019 елның 2 октябрендәге 49 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 61 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 69 номерлы үзгәрешләре белән) нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү билгеләргә:

- Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 16:33:181620:1712 кадастр номерлы, 6960 кв.м. мәйданлы, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Шигали авыл җирлеге, Яңа Шигали авылы, Парк урамы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Шигали авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең социаль объектлар зонасында (ОД-С) шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төре - «Кибетләр»гә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты.

2. Гавами тыңлауларны үткәрү оештыручысын билгеләргә – Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет).

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проект буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 01 августыннан 2025 елның 20 августына кадәрге чорда үткәрергә.

4. Гавами тыңлауларны үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә – 2025 елның 12 августында 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шигали авыл җирлеге, Иске

Шигали авылы, Үзәк урамы, 45 нче йорт (алга таба - Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).

5. Шигали авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында 2025 елның 11 августында 10 сәг. 00 мин. алып 16 сәг. 00 мин. кадәр (ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты: 12 сәг. 00 мин. дән 13 сәг. 00 мин. кадәр) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча проектның экспозициясен оештырырга: (https://pestreci.tatarstan.ru/zhizn-poseleniya-6828329.htm ) «Проектлар экспозициясе» бүлегендә.

6. Әлеге карарның 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән чор дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү хокукына ия:

- язма рәвештә яки электрон документ формасында гавами тыңлауларны оештыручы адресына, адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Иске Шигали авылы, Үзәк урамы, 45 нче йорт, e-mail: shig.pes@tatar.ru;
- проектлар экспозициясен карап чыгучыларны исәпкә алу китабында (журналында) язу аша, адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Иске Шигали авылы, Үзәк урамы, 45 нче йорт;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәргәндә язма яки телдән формада.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдим яки искәрмәнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.

7. Гавами тыңлаулар оештыручыга:

- әлеге рөхсәтләр сорала торган җир кишәрлекләре белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат җиткерергә;
- гавами тыңлаулар үткәрү турында белдерүне «Вперед» («Алга») район газетасында һәм Шигали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга;
- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча гавами тыңлаулар үткәрүне тәэмин итәргә.
- гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Гаризачы - З.Н. Хуҗәхмәтовка гражданга гавами тыңлаулар оештыруның сопровождениесен тәэмин итәргә, шул исәптән экспозиция үткәргәндә һәм әлеге рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә мәгълүмат җиткергәндә.

9. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы урынбасары Л.Т. Тарасова